СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

# КАРАР

2019 елның 30 нче октябре № 3

"Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегендә Чертуш авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Шахмай авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге башлыгы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чертуш авылында Сөембикә урамы буенча 1-18; Дуслык урамы буенчам 1-10 нче йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 20 ноябрь көнне сәгать 10.00 га Чертуш авылында Сөембикә урамы, 16 нчы йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чертуш авылында Яшьләр урамы буенча 1-28 нче йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 20 ноябрь көнне сәгать 14.00 га Чертуш авылында Яшьләр урамы, 16 нчы йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чертуш авылында Үзәк урам 32 нче йортта (Чертуш мәдәният йортында) Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын 2019 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Халык җыенын уткәрү өчен Чаллы Башы авылы халкы исемлеген бүлеп сайлау тәртибе территориаль бүленеш буенча башкарылырга тиеш.

5. Гражданнар җыены этапларын уткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, 75тән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Шахмай авылында түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?:

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү););
- юлларны кардан чистарту;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

"РИЗА" "КАРШЫ"

7. Әлеге карарны «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы И.Г.Гаризов